РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2023 елның 20 сентябре **№105**

2023 елга гражданнар керемнәренең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең чик кыйммәтләрен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү методикасы», «2023 елның беренче ярты еллыгына Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2023 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2022 елның 22 декабрендәге 1111/пр номерлы боерыгы, «Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе нормативын билгеләү методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 18 августындагы 584/пр номерлы боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьяларына таянып, ТР Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик кыйммәтләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек бәясе чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 661 158 сум.

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 322 316 сум.

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 1 983 474 сум.

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 644 632 сум.

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 3 305 790 сум.

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 3 966 948 сум.

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 628 106 сум.

1.1.8. сигез кешедән торган гаилә өчен – 5 289 264 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык гомуми керемнең чик кыйммәте күләме, исәп-хисап буенча (1 нче кушымта) түбәндәгечә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 14 353,89 сум.

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 28 707,78 сум.

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 43 061,67 сум.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы Р.Р.Хәйруллин